| Килешенде: | Килешенде: | Килешенде: | Раслыйм: |
| --- | --- | --- | --- |
| Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>______/Д.Ф.Шакиров/ | Балтач муниципаль районы Мәдәният бүлегежитәкчесе<br><br>________/И.И.Петров/ | Балтач муниципаль районы мәгариф идарәсе җитәкчесе<br><br>_____/Р.К Мөхәрләмов/ | Балтач муниципаль районы "Б.С.Рахимов исемендәге Кенә төп гомуми белем мәктәбе" директоры<br><br>_______/Р.В.Низамиев/ |

## "Халык зур ул, моңлы ул..." исемле татар җырының VIII төбәкара ачык конкурс-фестивален үткәрү турында нигезләмә

### 1. Гомуми мәгълүмат

Татарстан Республикасы Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы мәгариф идарәсе, Балтач муниципаль районы мәдәният бүлеге, Балтач муниципаль районы МБГБУ "Б.С.Рахимов исемендәге Кенә төп гомуми белем мәктәбе", "Халык зур ул, моңлы ул..." конкурс-фестивале (алга таба – фестиваль) үткәрә.

### 2. Фестивальнең максаты Һәм бурычлары:

-нәфис сүз осталарын барлау Һәм аларга иҗади үсеш өчен шартлар тудыру;
-татар телен, әдәбиятын Һәм мәдәниятен пропагандалау;
- татар милли музыкасы аша укучыларга мәдәни һәм әхлак тәрбиясе бирү;
- балаларның халык Һәм эстрада җырларын башкару сәләтләрен үстерү;
- татар халык иҗатын пропагандалау;
- якташларыбыз: Татарстанның атказанган артисты Җәвәһирә Сәләхова, Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимованың дәвамчыларын барлау.

### 3. Катнашучылар:

**"Халык зур ул, моңлы ул..."** зонаара ачык конкурс-фестивалендә 7 яшьтән алып 15 яшькә кадәрге гомуми белем бирүче мәктәп укучылары катнашырга мөмкин.

### 4. Фестивальне оештыручылар:

-Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты;
-Балтач муниципаль районы мәгариф бүлеге;
-Балтач муниципаль районы мәдәният бүлеге;
-Балтач муниципаль районы «Б.С.Рахимов исемендәге Кенә төп гомуми белем мәктәбе»;

### 5. Фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибе:

**5.1. "Халык зур ул, моңлы ул..."** конкурс-фестивале 2025 нчы елның 26 мартында үткәрелә.

Конкурста катнашырга теләүчеләр 11 нче марттан да соңга калмыйча, оештыру комитетына анкета-гаризаларын (Кушымта 1) конкурс почтасына җибәрергә тиеш. Зонаара конкурска мәктәпләрдән һәр номинациягә берәр номер кабул ителә.

**5.2**. Фестиваль яшь аралыгы буенча 2 төркемгә бүленеп үткәрелә:

7-10 яшьлек, 11-15 яшьлек балалар.

**5.3.** Номинацияләр:

- **композиторлар әсәрләре (соло);**
- **фольклор (җырлы-биюле композиция);**
- **нәфис сүз;**
- **татар халык җырлары (соло).**

**5.4.**Конкурс-фестивальдә катнашучыларның номеры гаризалар килү тәртибендә төзелә.

**5.5.**Фестивальдә катнашучының җырны үз тавышы белән башкаруы шарт.

**6. Конкурс-фестивальнең эш тәртибе:**

Конкурс ике этапта үткәрелә: читтән торып һәм турыдан-туры. Конкурсантларның эшләре электрон **почтаның болытына (Облако)** эленә. Сылтамасы катнашучының анкета-гаризасына куела, фестиваль почтасына җибәрелә. Видеороликларның разрешениесе **640х480** нән ким булмаска тиеш.

**7. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү:**

Жюри эшләрне карап, һәр номинациядән иң яхшы дип табылган 7 катнашучыны комиссия алдында чыгыш ясарга чакыра. Биредә җиңүчеләр билгеләнә. Җиңүчеләр Гала–концертта, бүләкләү өлешендә катнаша. Аларга дипломнар Һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының истәлекле бүләкләре тапшырыла. Килеп катнашучыларның призлы урынга кермәгәннәре лауреат була. Фестивальдә катнашкан барлык укучыларга да электрон сертификатлар җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре оештыручының рәсми сайтында, социаль челтәрендә урнаштырыла Һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басыла.

**8.Белешмәләр өчен адреслар һәм телефоннар:**

Электрон почта адресы: festival-knya @yandex.ru

422266, Балтач районы, Мәктәп урамы, 5а нчы йорт. Телефон/факс: 8(84368)2-85-56; 89172999494 (тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Сибгатуллина Гөлшат Наил кызы)

Кушымта 1

**“Халык зур ул, моңлы ул...” исемле татар җырының зонанара ачык конкурс-фестивалендә катнашу өчен гариза**

| | |
|---|---|
| Хронометражы күрсәтелгән башкару программасы (Мәсәлән, җырның исеме һәм вакыты) | |
| Номинация | |
| Башкаручының фамилиясе, исеме (тулы килеш) | |
| Җитәкченең фамилиясе, исеме (тулы килеш), телефон номеры | |
| Башкаручының яше | |
| Оешма (устав буенча), адрес һәм телефон | |
| Болытның (Облако) сылтамасы | |